

ПРЕЗИДЕНТ ИМЗАСЫ
Рөстәм Миңнеханов Көнчыгыш икътисади форумында катнаша
> 2

ВЯЧЕСЛАВ ДАНИЛОВ:
«Архив документларына нигезләнгән тарихка каршы килеп булмый»
> 3

ЗНАРОК КОМАНДАСЫ
«Ак барс» яңа сезондагы тәүге җиңүен яулады
> 4

КАЗАНДА ОЧРАШУ
Башкалада халыкара мөселман киносы фестивале башлана
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 130 (28903) | Чәршәмбе | 7 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

Мәгариф

ЙОКЫМЫ, УКУМЫ?

РЕСПУБЛИКАДА БИШ КӨНЛЕККӘ КҮЧКӘН МӘКТӘПЛӘР САНЫ АРТА

Шимбә укымыйк әле! Ел саен яңа уку елы алдыннан әти-әниләр әнә шундый бәхетле көнгә өметләнә. Быел да биш көнлек укытуга күчү турында сөйләшүләр күп булды. Ахыр чиктә мәктәпләр бу мәсьәләне ничек хәл иткән? Ике көн ял итүнең нинди уңай һәм тискәре яклары бар?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хәзерге вакытта республикада барлык 1 нче сыйныф һәм коррекцион мәктәпләрдәге укучылар атнага биш көн генә укый. Узган уку елында Түбән Кама районындагы 17 мәктәптә башлангыч сыйныфларда белем алучы 10 мең укучы шундый тәртиптә белем алган иде. Быел районның тагын 20 мәктәбе бу тәҗрибәне үзләрендә сынап карарга булган дигән мәгълүмат бар. Хәзерге вакытта Казанда 12 нче, 35 нче, 121 нче мәктәпләр, 7 нче гимназия, 183 нче лицейда биш көнлек укыту тәртибе кертелгән. Кайберәүләрендә бөтен мәктәп, ягъни 11 нче сыйныфлар да биш көнлеккә күчкән.

Түбән Камадагы 32 нче гимназиягә исә бу яңалык кагылмый. Алар элеккеге тәртиптә укуларын дәвам итә. Дөрес, әйтик, укытучы Елена Гаранина биш көн уку яклы. «Әти-әниләрнең ялларны балалар белән бергәләп уздыра алуы бик яхшы бит. Бер генә көн ял бик аз ул», – дигән фикердә.

Түбән Каманың 31 нче мәктәбендә балалар атнага ике көн ял итә. Биш көнлек укуның уңай һәм тискәре яклары турында мәктәпнең элеккеге директоры Рәшит Галиәхмәтовтан сораштык. Ул август аенда гына лаеклы ялга киткән икән.

– Биш көнлек укыту – бик кирәкле әйбер, – ди ул. – Тәрбиягә урын күбрәк кала. Балалар атна буе әти-әниләрен юньләп күрмиләр дә бит. Ял көннәрендә бергәләшеп өй җыештыралармы, походка, футболга, спорт чараларына, кунакка баралармы – бик зур тәрбия эше алып барылачак. Әти-әниләр тәрбия бирмәсә, мәктәп кенә биреп бетерә алмый аны. Укытучылар өчен шимбә – ял көне түгел. Алар әти-әниләр белән аралаша, төрле түгәрәкләр алып бара. Әлбәттә, кайбер дәресләр санын кыскартмыйча булмый. Физкультура, рус һәм татар телләрен кыскарта идек. Мәгариф бүлегеннән нинди фәнне кыскартып була, нәрсәне булмый дигән күрсәтмә бирелә. Эш шуңа карап оештырыла. Татар телен дәрестә генә өйрәтеп калмыйча, тәрбияне татарча алып бару отышлы.

Казандагы 183 нче лицейда да биш көн генә укыйлар хәзер. Рәхилә Гобәйдуллинаның ике баласы укый анда: беренче һәм алтынчы сыйныфларда.

– Бик рәхәт. Авылга кайтканда да сорап китәсе юк. Балаларны да теләгән җиргә алып барырга мөмкин. Алар белән ял итәргә вакыт күбрәк кала. Баланың гына түгел, әти-әнинең дә йокысы туя. Атна буе эшләгәч, барыбызның да озаграк йоклыйсы килә бит ул. Моның бернинди гаебе дә юк. Бөтен әти-әниләр дә канәгать, – ди ул, сөенеп.

Башка әти-әниләр дә, бернинди авырлыгын да сизмибез, диләр. «Гадәттә, шимбә көнне юньле дәрес куймыйлар. Ә мәктәпкә барыбер барырга кирәк. Биш көнгә күчүгә бик сөенәбез. Дәресләр саны артканны сизмәдек тә», – ди ике бала әнисе Эльвира.

Казандагы этномәдәни компонентлы 12 нче яһүдиләр мәктәбе бу системага 1998 елдан ук күчкән. Монда барлыгы 700дән артык бала укый. Бөтен сыйныфлар – биш көнлектә.

Ахыры 3 нче биттә >

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы аңлатмасы:
– Биш көнлек уку атнасына күчү турында карарны уку йортлары үзе кабул итә. Министрлык бу эшкә катнашмый. Белем бирү программалары федераль стандартларга туры китереп төзелергә тиеш. Монда барлык сыйныфларда өйрәнелә торган фәннәр саны, дәресләрнең артык күп булмавы, укытучылар штаты исәпкә алына. Артык дәрес куярга ярамый, СанПиН нормалары бар. Мәктәпләр уку һәм укудан тыш нагрузканы билгели. Биш көн укыту өчен әти-әниләргә мәктәп җитәкчелегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Арзанлы ипотека бетми

Яңа йортлардан торак алучыларга 7 процентлы ташламалы ипотека озайтылырга мөмкин. Бу хакта Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Никита Стасишин Көнчыгыш икътисади форумында ТАСС хәбәрчесе белән әңгәмәсендә белдергән. Әмма әлеге мәсьәлә буенча тиешле карар сораштыру нәтиҗәләренә таянып кына кабул ителәчәк. Аның әйтүенчә, министрлык 9–12 процентлы ставка чорында ипотека алучыларга аны киметүгә ярдәм итүне күздә тота. Халыкның фатир сатып алудан вакытлыча тыелып торуы сәбәпле, алдагы берничә ел дәвамында торакка ихтыяҗның зур булуы көтелә. Ә моның өчен ташламалы программалар кимендә шушы чорда «эшләргә» тиеш.

Сүз уңаеннан, Россия Финанс министрлыгы 6 процентлы гаилә ипотекасын киләсе елның 31 декабренә хәтле озайтырга тәкъдим итте. Аны 2023 ел ахырына кадәр баласы туган гаиләләргә бирү күздә тотыла.

Түләү күләме билгеле

Татарстан Министрлар Кабинеты киләсе елга айлык акчалата түләү күләмнәрен билгеләгән. Хөкүмәтнең бу җәһәттән тиешле карарын Премьер-министр Алексей Песошин имзалаган.

Шулай итеп, 2023 елның 1 гыйнварыннан социаль түләүләр һәм субсидияләр 1,061 процентка арттырылачак. Биредә сүз хезмәт ветераннарына, дәүләт бүләкләренә лаек булучыларга, реабилитацияләнгән кешеләргә, ятим балаларга һ.б. түләүләр турында бара. Документка караганда, 2023 елда хезмәт ветераннарына, дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүчеләргә айлык түләү күләме – 581 сум (быел 547 сум), сәяси репрессияләрдән зыян күрүчеләргә – 727 сум (быел 685 сум), сугыш елларында тылда кимендә 6 ай эшләгән кешеләргә – 867 сум (быел 817 сум), ятимнәргә (мәктәпкәчә яшьтәге балаларга) – 10326 сум (быел 9732 сум) һәм мәктәп яшендәге балаларга 11907 сум (быел 11222 сум) тәшкил итәчәк.

Ятимнәргә юл йөрүгә айлык субсидия күләме киләсе елда 354 сумга җитәчәк.

Көннән-көн күбәя

Узган тәүлектә Татарстанда 552 кешенең коронавирус йоктыруы ачыкланган. Алдагы көнне чир йоктыруның 514 очрагы теркәлгән булган. «Стопкоронавирус.рф» хәбәр иткәнчә, 77 сырхау (бер көн элегрәк – 35) хастаханәгә салынган.

Соңгы мәгълүматларга караганда, пандемия башланганнан бирле Татарстанда инфекция ияртүнең 160234 очрагы рәсми теркәлгән. 151326 кеше савыккан, шул исәптән 103е – соңгы тәүлектә (алдагы көнне – 78). Шул ук вакытта төбәктә тагын 2 кешенең коронавирустан вафат булуы рәсми танылган. Шулай итеп, республикада Covid-19 инфекциясеннән үлүчеләр саны 2003кә җиткән.

Авыру көчәю сәбәпле, Роспотребнадзор битлек киеп йөрергә киңәш итә. Хөкүмәт карарында да шундый ук тәкъдим бар. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов август азагында коронавируска каршы көрәш буенча оператив штаб эшен яңартып җибәрде.

Урак өсте

Бәрәкәте булсын!

Татарстан игенчеләре сөенчеләре белән бүлеште. Сезон башыннан ук өметләнеп көткән 5 миллион тонна ашлык җыеп алынды.

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының соңгы мәгълүматлары буенча, әлегә ашлык 1357 мең гектар мәйданда урып җыелган, бу – барлык мәйданның 94 проценты дигән сүз. Димәк, ел буе дулкынланып һәм зур өметләр баглап көткән урып-җыю кампаниясе акрынлап ахырына якынлаша. Быел уңыш та, уңдырышлылык та мулдан булды. Татарстанда уртача уңыш гектарыннан 36,8 центнер чыга. Хуҗалыклар арасында гектарыннан 70–80 центнер алып, рекорд куючылар да юк түгел.

Инде урып-җыю эшләрен тулысынча төгәлләгән районнар да бар. Алар – Әтнә, Нурлат, Кукмара, Балтач һәм Югары Ослан районнары.

Кукмара игенчеләренең шатлыкларын без дә уртаклаштык. Әлеге район, башкалар белән чагыштырганда, уракка соңрак чыккан иде. Тик аңа карамастан, эшләрен беренчеләрдән булып тәмамлады.

– Урып-җыюга катнашы булган һәркем бик тырышып эшләде. Һәр урында тырыш, җаваплы, үз эшенең осталары эшләгәндә әнә шундый нәтиҗәләргә ирешергә була. Егетләргә дә, хатын-кызларыбызга да зур рәхмәт, алар – молодец! – диде безгә районның баш агрономы Илдар Габбасов. – Бу чорда бер генә эш тә җиңел бармый инде ул. Авырлыклары да, хәл итәсе мәсьәләләре дә гел килеп чыгып кына тора. Башкача була да алмый. Быел уңыш мул булды. Шуны вакытында, бер бөртеген дә сарыф итмичә җыеп алырга кирәк иде. Игеннәрне җил аударганлыктан, комбайнчыларга бик авырга туры килде. Ләкин алар сынатмады.

Аның сүзләренчә, әлегә район кырларыннан техник культураларны җыеп аласы калган.

Кайсыдыр районнар беренчелек белән алдырса, кайсылары мул уңыш белән горурлана ала. Тәтеш – 214,5 мең, Буа – 198,7 мең, Арча 197 мең тонна ашлык җыеп алган. Беренче бишлектә Мөслим һәм Минзәлә районнары да бар.

Әлеге вакытта районнар рапс культурасын җыю белән мәшгуль. Шулай ук күбесенең кырлардан яшелчәләр, шикәр чөгендере, көнбагыш җыеп аласылары бар әле.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Олег АПОЛИХИН, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының репродуктив сәламәтлек буенча баш белгече:

Бүгенге ир-егетләр нинди? Коры-сары ашыйлар, хәмер кулланалар, тәмәке тарталар, дару эчәләр. Стресс һәм экология йогынтысы да бар. Җенси көчсезлек барлыкка килә, аларның хәле юк, үзләре ачулы. Хатыннары ашарга салганда гына җанланалар. Һәрвакыт йоклыйлар, тормыштан зарланалар, барысына да сәясәтчеләр, хакимият һәм хатыннары гаепле дип саныйлар. Аннары хәмергә үреләләр.

(Көнчыгыш икътисади форумында сөйләгәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – СӘҮДӘ

Быелның гыйнвар – июнь айларында республикада ваклап сату күләме 581 млрд сумны тәшкил иткән. Шуның 266 млрд сумнан артыгы – азык-төлек, калганы сәнәгать товарларына туры килә.

НӘРСӘ КҮПМЕ САТЫЛГАН? *(миллиард сумнарда)*

Бензин һәм дизель ягулыгы	45,2
Җиңел автомобильләр	38,6
Кием-салым	36,9
Ит һәм ит ризыклары	31,7
Дару	19,7
Тәмәке	13,3
Ипи һәм кумәч	13
Косметика һәм парфюмерия	11,8

Октябрь җиле исә

Татарстанда сентябрь ае кинәт кенә суытудан һәм тәүге кыраулардан башланып китте. Әмма кар тиз генә төшмәячәк әле. Якын араларда Татарстан башкаласында һава температурасы нормадан чама белән 4–5 градуска түбәнрәк булачак. Тәүлеклек уртача температура инде хәзер үк нибары 10 градус тәшкил итә. Бу – нормадан 4–5 градуска кимрәк. Казан федераль университеты профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев «Татар-информ» хәбәрчесенә шулай дип белдергән. «Казанда тәүлеклек уртача температураның +10 градустан кимүе гадәттә 19–22 сентябрьгә, шәһәр читендә тәүге кырау төшү – 29 сентябрьгә, шәһәр эчендә – 4 октябрьгә, туфракта – 16–20 сентябрьгә туры килә», – ди профессор. Аның әйтүенчә, Казанда тәүлеклек уртача температураның 0 градустан түбәнәюе гадәттә октябрь азагы – ноябрь башында күзәтелә. Шушы вакытта беренче кар ява.

Галим әйтүенчә, быел Казанда сентябрь башындагы һава торышы октябрьгә күбрәк туры килә.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ЯҢА ТЭТЧЕР» КИЛДЕМЕ?

Июль аенда Англиядә җиңелчә генә сәяси җир тетрәү булып алган иде. Министрлар кабинетын илледән артык чиновник ташлап чыккач, премьер Джонсон отставкага китәргә мәҗбүр булды. Крис Пинчер атлы әхлакый яктан бозык адәмне шахмат тактасына тартып чыгаруы өчен партиядәшләре аны кичермәде. Сәхнә артынданиләр булуын без белмибез, әмма премьерның портфель белән сабуллашуын халыкара җәмәгатьчелеккә шулай аңлаттылар. Джонсонның үз әхлагы да шактый сораулар тудыра һәм хөкүмәт җитәкчесе аннан алда да бер җәнҗалдан соң иярдән чак кына авып төшмәгән иде. Июльдәге «ат йөреше» аның өчен соңгысы булып чыкты. Дөрес, яңа премьер сайланганчы, 5 сентябрьгә кадәр түнтәрелгән премьер идарә камытын салмады. Нәкъ менә шул көнне Консерватив партия хөкүмәтнең яңа җитәкчесен игълан итәргә тиеш иде.

Июльдә Джонсонның отставкасы Мәскәүдә җиңелчә генә җанлану тудырды. Украин кризисында Киевка аркадашлык кылып, британ җитәкчесе Кремльнең ачуын бик чыгарды бит. Россия Тышкы эшләр министрлыгы вәкиле Мария Захарова үзенең телеграм-каналында: «Британиянең ярымтаркалу вазгыяте шом тудыра. Идарәсезлек, хаос, пике – экспертлар биргән төп характеристикалар шулар», – дип язып куйды. Әмма Бөекбританиянең сәяси Олимпында әллә ни үзгәрешләр тумады. Консерватив партиянең буталчык сайлау сукмагындагы барлык борылышларны уңышлы үтеп, Лиз Трасс – Джонсон кабинетының тышкы эшләр министры – премьер-министр итеп сайланды. Чит ил телевидениеләренең сәяси тапшыруларын күп караган кешеләр Трасс ханымны яхшы белә. Сәяси белдерүләр белән еш чыгыш ясый ул. Дүшәмбе көнне сәгать 14.30да аның, шул ук Джонсон кабинетындагы элекке финанс министры Риши Сунакны җиңеп, премьер портфелен үз кулына алуын игълан иттеләр.

Яңа премьер, сайланганчы ук, идарәче камытын киюгә, чит ил җитәкчеләреннән иң беренче Зеленскийга шалтыратачагын әйткән иде. Димәк, Бөекбритания – Россия мөнәсәбәтләрендә ниндидер үзгәреш булса да, бары тик тагын да начараюга таба гына.

Әйе, Англиядә вазгыять бик начар. Лиз Трасс үзен «тимер леди» Маргарет Тэтчер кебек тотарга вәгъдә итә. Үткән гасырның сиксәненче елларында, британнарны кытыршы бияләй белән тотып, ил икътисадын тәртипкә китергән, СССРның җеназасына үзеннән өлеш керткән Тэтчерны Англиядә дә, Россиядә дә яхшы хәтерлиләр әле. Яңа премьерның аны идеал итеп алуы Бөекбританиянең эчке сәясәтендә уңышларга китерерме, анысын әйтеп булмый. Бер нәрсә хак: традицион Англия – Россия каршылыгы үсәчәк. Трасс үзе дә «Путинны туктатырга» җыенуын игълан итте инде. Россия Тышкы эшләр министрлыгының Европа департаменты директоры Сергей Беляев: «Лиз Трасс Бөекбританиянең Консерватив партия җитәкчесе итеп сайланганнан соң, Россия ике ил арасында мөнәсәбәтләр яхшы якка үзгәрер дип көтми», – диде. Хәер, җитәкчелеккә Риши Сунак килсә дә, хәл шундый ук булыр иде.

Россиядә

ИПОТЕКА ИПОТЕКАДАН АЕРЫЛА

Россиялеләр алган кредитларда ипотека өлеше 50 процентка җиткән. Бу ил тарихында беренче тапкыр күзәтелә. Хәзер бурычка алмыйча фатирлы булу яисә йорт торгызу – мөшкел эш. Күчемсез милеккә бәяләр, бөтен түшәмнәрне җимереп, югарыга сикерә. Төзелеш материаллары һәм сантехника янына якын килә торган түгел. Хәер, бәяләрнең шундый югарылыгы ул – ипотека нәтиҗәсе. Ясалма ихтыяҗ тудырып, бәяләрне шулай биетәләр. Банкларга майлы калҗа китерә ипотека, бурыч түләүчеләрнең исә җелеген суыра. Әҗәткә фатир алучылар ничек итсә итәләр, бурычларын билләрен кысып буып булса да түлиләр. Илдә куллану кредитларын түләмәүчеләр саны рекордлы рәвештә үсә, әмма ипотека түләмәүчеләр бик аз, юк диярлек. Фатирдан колак кагу куркынычы кешеләрне бар көчкә җигелеп алга атларга мәҗбүр итә. Быелның беренче июленә ипотека бурычының күләме 12,7 триллион сумга җиткән инде. Халык күбрәк өстенлекле ипотекага ирешергә омтыла. Процентларның түбән булуы кызыктыра. Әмма бәяләрнең югарыга үрләве бу өстенлекне юкка чыгара, моны сизмисең генә.

Хисап палатасы, нәкъ менә шул вазгыятьне аңлап, өстенлекле ипотекага каршы чыкты. Аудитор Наталья Трунова яңа төзелә торган йортларга өстенлекле ипотека базарда кыенлыклар китереп чыгара дип саный. Икенчел торак белән яңа фатирлар бәяләренең кискен аерылуын мисал итеп китерә. Соңгы айларда Россиядә ипотека алучылар саны үсә, әмма 2021 ел дәрәҗәсенә җитмәде әле.

Торак ипотекасы төзелеш тармагын тотып тора, билгеле. Ипотека бирү тукталса, тармак иртәгә үк җимереләчәк. Ипотека булганда да җимерелү котылгысыз, әлбәттә, әмма анысы – ерак киләчәк эше.

Торак ипотекасы әлегә үз мөмкинлекләрен тулысынча файдаланып бетермәде, базарда яңа төр льготалы ипотекага старт бирелә. Бу юлы хөкүмәт җитештерү мәйданнарын ишәйтмәкче. Сәнәгать предприятиеләре яңа җитештерү цехлары ачарга телиләр икән, рәхим итеп яңа программада катнаша алалар. Бу максатка озак сроклы, түбән процентлы ипотека кредиты бирелә башлаячак. Кредитны түләүнең срогы – җиде ел, проценты – биш. Инновацион предприятиеләргә кредит 3 кенә процент белән бирелә. Бурычның максималь күләме – 500 миллион сум. Вице-премьер Денис Мантуров, бу акчага 10 мең квадрат метрлы җитештерү мәйданы алырга була, бу уртача зурлыктагы завод ачарга җитә, дип саный. Бу рәвешле җитештерү мәйданы сатып алу яңа продукция җитештерүне бер-ике ел алдан башларга мөмкинлек бирә дип тә санала. Дүртенче кварталда, тагын берничә атнадан, кредит алу өчен чиратка басарга була инде. Әлегә бизнесның бу яңалыкка ничек каравы мәгълүм түгел. Эшмәкәрләр чиратка бассалар һәм кредит бирелә башласа, бәяләр күтәрелеп, 500 миллионга ун мең квадрат метрлы күчемсез милек алып булуы гына бераз шикләндерә.

КӨНЧЫГЫШТА КИЛЕШҮ

tatarstan.ru

Татарстанга Владивостоктан товар төялгән беренче поезд килә. Хакасия, Иркутск һәм Камчатка белән хезмәттәшлекне ныгытачаклар. Президент Рөстәм Миңнеханов, Владивостокта берничә очрашу уздырып, киләчәк турында сөйләште. Анда ул Көнчыгыш икътисади форумында катнашу өчен барды.

Беренчесе юлга чыкты

Иң элек Рөстәм Миңнеханов Владивостокның диңгез сәүдә портында булды. Россиянең Ерак Көнчыгыштагы иң зур порты бу. Ул елына 5 миллион тонна йөк һәм нефть продуктлары, 150 мең берәмлек машина һәм тәгәрмәчле техника, 670 мең контейнер йөге үткәрергә сәләтле.

Әлеге портта Рөстәм Миңнеханов FESCO транспорт оешмасының логистика бүлеге вице-президенты Герман Маслов белән дә очрашты. Хәтерләсәгез, июль аенда әлеге оешма вәкилләре, Татарстанга килеп, республикада терминал-логистика үзәге ачу мөмкинлекләрен тикшергән иде.

Владивостокның диңгез портында Рөстәм Миңнеханов машина, универсаль, контейнер терминалларын карады. Моннан тыш Президент Татарстанга Азия – Тын океан төбәге (АТР) илләреннән товар төялгән беренче поездны озатуда да катнашты. Айга ике тапкыр Владивосток станциясеннән Тихорецкая станциясенә кадәр хәрәкәт итәчәк әлеге поезд 11 тәүлек юлда булачак. Моңа кадәр күп кенә товарларны Мәскәү аша алып кайтканнар.

«Компаниябезгә ышаныч күрсәтүегез өчен рәхмәт! Без, базарларны өйрәнеп, Татарстанда сәнәгатьнең, интернет-сәүдәнең ничек үсүен күрдек. Зур хезмәттәшлеккә өметләнәбез. Кытай, АТР илләре белән Татарстан арасында «күпер» салырга өметләнәбез», – диде Герман Маслов. Рөстәм Миңнеханов, үз чиратында, ирешелгәннәр белән генә чикләнмәскә чакырды. «Азия – Тын океан илләреннән тыш безгә Төркия белән Иран базарларын да өйрәнергә кирәк», – диде ул. Татарстан Хөкүмәте белән «FESCO транспорт төркеме» арасында килешүгә кул куелды.

Порт яңартылачак

Транспорт димәктән, Владивостокта Казанның Елга порты территориясенә яңа сулыш өрү турында сөйләштеләр. Бу хактагы килешүне Казан мэры Илсур Метшин белән «Сбербанк» идарәчесе рәисенең беренче урынбасары Александр Ведяхин имзалады. Якынча исәпләүләр буенча, 287 га мәйданны тәртипкә китерүгә 500 миллиард сум чамасы акча сарыф ителәчәк. Әлегә бу урында иске склад, ташландык биналар урнашкан. «Казанның порт өлеше – шәһәребезнең төп үсеш нокталарының берсе. Республика һәм башкала халкының яшәү шартларын яхшыртудан тыш, өстәмә эш урыннары да булдырылачак, төрле тармактагы белгечләр җәлеп ителәчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Елга портының ташландык өлешендә якын киләчәктә 1,5 миллион квадрат метр мәйданда торак, 1,3 миллион квадрат метр мәйданда административ биналар пәйда булачак. Моннан тыш килешү нигезендә 12 чакрым озынлыкта яр буен да төзекләндерергә җыеналар.

Ерак булу куркытмый

Рөстәм Миңнехановның эш сәфәре кысасында Хакасия Республикасы белән Татарстан арасында да килешү имзаланды, аны тормышка ашыру өчен күреләсе чаралар расланды. Моннан алдагы килешү 2016 елда төзелгән иде. «Ике төбәкнең барлык өлкәләрдә дә хезмәттәшлек өчен мөмкинлекләре күп. Әлегә ике арадагы товар әйләнеше зур түгел – 240 миллион сум чамасы тәшкил итә. Без «КамАЗ» машиналары һәм аларга яраклы запчасть, шиннарны күбрәк кертергә әзер», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан белән Иркутск өлкәсе арасындагы мөнәсәбәтләрне дә ныгытырга килештеләр. Владивостоктагы очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов белән Иркутск өлкәсе губернаторы Игорь Кобзев 2025 елга кадәр хезмәттәшлек турында килешүне тормышка ашыру чаралары планын имзалады. Игорь Кобзев Татарстандагы министрлык һәм ведомстволарда эшнең ни рәвешле оештырылуы белән кызыксынуларын да әйтте.

Икътисади форум кысасында Татарстан белән Камчатка крае арасында да сәүдә-икътисад, фән-техника һәм мәдәният тармакларында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. «Ике төбәк арасындагы товар әйләнеше әлегә зур түгел. Татарстан «КамАЗ» һәм йөк машиналарына, автобусларга запчастьлар, шиннар җибәрә. Без Камчатка краеннан балык һәм эшкәртелгән балык продуктлары кабул итәбез. Без «КамАЗ» машиналары белән аларга кирәкле запчастьларны күбрәк җибәрергә, суднолар төзелеш тармагында хезмәттәшлекне көчәйтергә әзер», – ди Рөстәм Миңнеханов. Президент фикеренчә, ара ерак булуга карамастан, ике төбәк арасында туризмны гына түгел, икътисади хезмәттәшлекне көчәйтү өчен дә мөмкинлекләр бар.

Татарстан Президенты Владивостокта «Ерак Көнчыгыш диңгез пароходчылыгы» җәмгыятенең Директорлар советы рәисе Андрей Северилов белән дә очрашты. Ростуризм башлыгы Зарина Догузова белән очрашуда исә республикада туристлык тармагын үстерү мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

ДУСЛЫК КҮПЕРЕ – МӘДӘНИЯТ АША

7–8 сентябрьдә Татарстанда Казахстан мәдәнияте көннәре узачак. Программа кысасында нинди чаралар көтелә? Матбугат очрашуында әнә шулар хакында сөйләделәр.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләренчә, Казахстан белән хезмәттәшлек – республика көндәлек эшенең аерылгысыз өлеше.

– Безнең мөнәсәбәтләрне мәдәният көннәрен үткәрү форматына гына калдырырга ярамый. Ул ике көн белән генә чикләнми, без һәрвакыт элемтәдә, бергә бик күп чаралар оештырабыз. Әле менә бу көннәрдә безнең зур иҗади делегация Сабан туе оештыру өчен Семейга бара. Минемчә, культуралар диалогы даими булырга тиеш, аны туктатырга ярамый. Шундый аралашу булганда гына, җәмгыятьнең гомуми культура дәрәҗәсе югары булачак, – диде министр.

Ирада Әюпова мәдәният көннәренең программасы белән таныштырды. Иртәгә Казанда башланачак халыкара мөселман киносы фестивале кысасында «Синема 5» кинотеатрында Казахстан фильмнары күрсәтеләчәк. Анда режиссер Юлия Захарованың «Тарлан», Адай Абельдиновның «Культегин» тарихи анимацион фильмы, Гөлнара Сарсенова, Вахтанги Хубудияның «Русские на Мариенплац», Британия кинорежиссеры Джесси Джонсонның «Аве Мария» һәм Фәрхәт Шәриповның «Схема» фильмнары тәкъдим ителәчәк.

«Тарлан» фильмы – Татарстан белән Казахстанның беренче уртак иҗади проекты. Ул ике дәүләт территориясендә төшерелгән.

– Бу – режиссерлар, авторлар, сценаристлар хөрмәтенә лаеклы безнең уртак эшебез. Фильмның сюжеты казах тамашачысына да, татарныкына да яхшы таныш. Ат ике халык өчен дә гомер-гомергә дус, ярдәмче, кадерле җан иясе булган, – диде фильм турында Казахстан Республикасының Казандагы генераль консулы Ерлан Искаков.

8 сентябрь кичке 6да Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Казахстан сәнгать осталарының гала-концерты була.

Ләйсән САФИНА

РЕКОРДЛЫ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

«АВГУСТ-ЛЕНИНОГОРСК» АГРОФИРМАСЫ ГЕКТАРЫННАН 88,5 ЦЕНТНЕР КӨЗГЕ БОДАЙ ҖЫЕП АЛГАН

Без Лениногорск районын нефть төбәге буларак кабул итәргә күнеккән. Тик соңгы бер-ике елда район авыл хуҗалыгы, аерым алганда, игенчелек буенча яхшы күрсәткечләргә ирешеп килә. Өч ел элек бирегә «Август-Лениногорск» агрофирмасы килеп, 35 мең гектар җирдә игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Бу – районның авыл хуҗалыгы җирләренең 50 проценты дигән сүз. Уңыш сере нидә?

Анна Арахамия

Электрон сервис

Ашлык кырлары, техника һәм игенчеләр уч төбендә шикелле. Оешма белгечләре Җир шарының кайсы гына почмагында булсалар да, кырлардагы барлык мәгълүмат телефон экранында күрсәтелә. «Август-Лениногорск» агрофирмасында әнә шундый замана таләпләренә туры килә торган программа эшли.

«Август-Агро» идарәче компаниясенең мониторинг һәм контроль бүлеге җитәкчесе Дмитрий Шаплыко сөйләвенчә, электрон сервислар барлык кырларны күзәтеп, эшне планлаштырырга ярдәм итә. Кайда нәрсә чәчелгән, узган ел монда нәрсә үскән, күпме ашлама кертелгән, никадәрле уңыш җыеп алынган, культуралар кайчан тишелеп чыккан һәм ничек үсә, күпмесе җыеп алынган, техника кайда эшли һәм күпме ягулык тотылган, нинди тизлек белән хәрәкәт итә, кайсы комбайнчы никадәр ашлык суктырган, амбарга күпме күләмдә икмәк кайткан... Хәтта тракторчы яки комбайнчының туктап ял итеп алуына кадәр барысын да бер экранда күзәтергә мөмкин. Чөнки бөтен авыл хуҗалыгы техникасына Gps җиһазы һәм ягулык күрсәтүче куелган.

– Һәр кырның үз карточкасы бар. Биредә барлык мәгълүмат тупланган, – дип аңлатты Дмитрий Шаплыко (рәсемдә). – Элек теге яки бу кырдагы хәлне белеп торыр өчен, агрономга гел йөреп торырга кирәк иде. Хәзер исә менә шушыннан гына да карап була. Мәсәлән, теге яки бу басудагы күрсәткечләр кинәт кенә төшеп китсә, белгеч машинасына утыра да шул урынга бара.

Анализ нәтиҗәләре буенча кайсы орлыкның яхшырак үсүен, ашламаны күпме кертергә кирәклеген, һава торышының нинди йогынты ясавын да ачыкларга мөмкин. Мәсәлән, аналитик нәтиҗәләр буенча, ашлама кая күбрәк кирәк – чәчү вакытында техника минераль матдәләрне автоматик рәвештә шунда күбрәк кертә. Сүз уңаеннан, идарәче компаниянең үз метеостанцияләренә кадәр бар. Алар агрономнарга бик нык ярдәм итә. Шунысы әһәмиятле: әлеге программадан җитәкчелек, агрономнар, инженерлар гына түгел, механизаторлар да файдалана ала.

Комбайнчылар үзләре ничек кабул итә соң мондый зур игътибарны? Агрономнар әйтүенчә, аларның үзләренә дә уңайлы, чөнки техника ватылган очракта, программа төзексезлекнең сәбәбен әйтеп бирә, теге яки бу эшне эшлисен алдан кисәтә. «Нәтиҗә безне куандыра. Уңдырышлылык республиканың уртача күрсәткечләреннән зуррак», – диде белгеч.

Җирне эшкәртмичә чәчү

Әйтергә кирәк, район үзенең таулы рельефлары белән үзенчәлекле. Биредә без тип-тигез, эшләр өчен уңайлы кырларны бик сирәк очраттык. Күпчелеге таулы-чокырлы, ташлы һәм кыялы. Шуңа күрә Лениногорскида эшләүче механизаторлар турында, чын виртуозлар, диләр. «Безнең районда читтән килгән комбайнчылар эшли алмый, ә менә безнекеләр, теләсә кая барып, осталыкларын күрсәтә ала. Чөнки мондый кырларда эшләп остарып бетәләр», – ди алар.

Безне исә Иске Шөгер авылы тирәсендәге гадәти булмаган кырга алып бардылар. Быел биредә гектарыннан 88,5 центнер (!) көзге бодай җыеп алганнар. Район өчен моңа кадәр күрелмәгән рекордлы күрсәткеч бу. Әлбәттә инде, без моның сере белән кызыксындык. Эш шунда ки, биредә культураларны җирне сөрмичә генә чәчәләр. «Август-Агро» идарәче компаниясен әлеге технологияне Татарстанда беренчеләрдән булып кулланучы дип әйтеп булмый, тик шундый зур масштабларда эшләүчеләр башка юк. Республикада 190 мең гектар җир no-till (ноу-тилл) технологиясе буенча эшкәртелә. Ягъни оешма эшли торган барлык тугыз районда да культураларны җирне эшкәртмичә генә чәчәләр.

Болай итеп эшләүнең өстенлекләре нидә соң? «Август-Агро» идарәче компаниясенең көнчыгыш төбәге буенча баш агрономы Илнар Харисов аңлатуынча, беренчедән, мондый ысул белән утыртканда җир дымны саклый, уңдырышлылыгы арта. Экология ягыннан да җир өчен файдалы. Ягъни җир катламнарына зыян килми, микроорганизмнар барысы да үз урынында кала. Җил, кояш туфрак катламын киптерми. Углекислый газ азрак оча. Икенчедән, чыгымнар һәм ресурслар ягыннан отышлы. Ягулыкка, техникага, запас частьларга чыгымнар 30–40 процентка кими.

– Мин ноу-тилл системасы белән 2013 елдан бирле эшлим, – ди Илнар Харисов. – Барлык технологиясен саклап эшләгәндә, традицион эшкәртүдәге кебек үк уңыш алырга мөмкин. Кайбер елларны хәтта күбрәк тә алып була.

Илнар Харисов аңлатуынча, болай итеп эшләгәндә аерым бер шартларны үтәргә кирәк. Беренчедән, культураларны ел саен аралаштырып утырталар: рапс – язгы бодай – көнбагыш – көзге бодай. Аларның һәркайсының үз бурычы бар. Кайберләре туфракны йомшарта, икенчеләре тирәнәйтә. Бер культураны алгач, икенче елга бераз юнәлешен үзгәртеп, икенче культураны турыга чәчәләр. Икенчедән, «КамАЗ» кебек авыр йөк машиналары бервакытта та иген басуларына керми. Ягъни комбайн бункерлары җиңелрәк техникага бушатыла да, юл читендә көтеп торган йөк машинасына төялә.

Лениногорскида әлеге технологияне өченче ел кулланалар. Тик көтелгән нәтиҗәләрне алыр өчен, берничә ел сабыр итәргә кирәк, ди белгечләр. Шул вакыт эчендә туфракның уңдырышлы өске катламы барлыкка килергә тиеш икән.

Ферма

Соңгы ике елда районда сөт күләме дә ике тапкыр арткан. Быел исә Ялтау авылында 400 башка исәпләнгән яңа ферма ачылган. «Август-Лениногорск» җәмгыятенең директор урынбасары Фоат Саматов сүзләре буенча, моңа кадәр авылда ике ферма булган. 1,5 ел эчендә «карусель» системасындагы ферманы сафка бастырганнар.

– Таналарның бер өлешен – Германиядән, бер өлешен Воронеждан алып кайттык. Алар бозаулап, терлекләр саны артты. Сыерлар көненә өч тапкыр савыла. Элек бер сыер тәүлегенә 12 литр сөт бирә иде, хәзер 28 литр сөт савып алабыз. Мондый күрсәткечләргә терлекләрнең туклану рационын үзгәрткәч ирештек, – диде Фоат Саматов.

Рәгать ХӨСӘЕНОВ, Лениногорск районы башлыгы:
– Беренчедән, районда сыерлар саны кимеде, ә сөт күләме артты. Икенчедән, «Август-Лениногорск» агрофирмасы яңа фермалар төзеде, искеләрен төзекләндерде. Бу безнең өчен бик яхшы. Оешма килү белән районда игенчелек культурасы үзгәрде. Яңа технологияләр куллану нәтиҗәсендә, елдан-ел уңдырышлылык арта. Без районга килгән инвесторлар алдына бурыч куябыз: халыкка да социаль ярдәм күрсәтелергә тиеш. Һәм моны сизәбез дә. Матди ярдәм күрсәтә, терлек азыгы бирә, үзләренә зыянга булса да, халыкка кирәк кадәр салам, печән кырларын тәкъдим итә. Кыскасы, бер-беребезне аңлап эшлибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕР МАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ӨСТӘМӘ САЙЛАУГА ТЕРКӘЛГӘН КАНДИДАТЛАРНЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

МАТЕРИАЛЛАР АВТОР ӘШКӘРТҮЕНДӘ БАСТЫРЫЛА. АЛАРНЫ ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ УРНАШТЫРУ БАСМА МӘЙДАН БУЛУ БУЕНЧА ҮТКӘРЕЛГӘН ЖИРӘБӘ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

№ 14 Пионер
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Анисимов Д.А.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 14 Пионер
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Нәгыймова В.А.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 7 Ибраһимов
бер мандатлы сайлау округы



Теркәлгән кандидат Хөснетдинов Д.Ф.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 14 Пионер
бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Федотов О.П.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыклары, коронавирус инфекциясе (COVID-19) эпидемиясе чорында медицина ярдәмен оештыру һәм күрсәтүдәге казанышлары өчен «Казан шәһәре «РЖД-Медицина» клиник хастаханәсе» хосусый сәламәтлек саклау учреждениесе табибы **Егоров** Роман Анатольевич, «Казан шәһәре «РЖД-Медицина» клиник хастаханәсе» хосусый сәламәтлек саклау учреждениесе санитаркасы **Пирогова** Алена Игоревна, «Казан шәһәре «РЖД-Медицина» клиник хастаханәсе» хосусый сәламәтлек саклау учреждениесе табибы **Рөстәмов** Мәәриф Нәзир углы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Лука Крымский медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары **Лодвигова** Евгения Анатольевна Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Тәтеш районы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Сөләйманов** Илдар Флер улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе урынбасары **Нугаев** Камил Әсгать улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсе бүлеге башлыгы **Фомичева** Гүзәлия Бәһрам кызы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

ТАРИХИ ДӨРЕСЛЕК ЮЛЫНДА



«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Миллият

Егерме елдан артык гомерен туган төбәген өйрәнүгә багышлаган Вячеслав ДАНИЛОВ редакциядә уй-фикерләре белән уртаклашты. Тиздән аңа 85 яшь тула. Берәү булса, шушы яшьтәге егәрлегенә, егетләрчә йөгереп йөрүенә шатланыр гына иде, әмма ул түгел. «Эшем күп, өлгерә алмам дип куркам», – ди.

– Пенсиягә чыккач, илебез архивларында бик озак казынып, Кайбыч районындагы туган авылым Хуҗа Хәсән турында ике китап бастырып чыгардым. Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкләрне өйрәнү институты үтенечен үтәү йөзеннән, быел Кайбыч һәм Апас районнарындагы 15 авылның тарихын язып бирдем. Бу эшләрнең барысы да пенсия акчасы һәм улларымның ярдәме белән эшләнде. Тау ягына багышлап язылган тагын ике китапның кульязмасы нәшер итүне көтеп ята. Ни кызганыч, иганәчеләр таба алмыйм. Моннан ике ел элек туган авылымда шулай ук улларымның ярдәме белән ике катлы бина салып, Татарстан Республикасының Тау ягы татар керәшеннәре музеен ачу насыйп булды. Дөрес, эшне башлап җибәргәндә, Мәдәният министрлыгы җитәкчеләре: «Сез изге эш башкарасыз, булышырбыз, грантлар да бирербез», – дип вәгъдә иткәннәр иде. Күренмәде. Югыйсә бу бит – Россия күләмендә бердәнбер татар керәшеннәре музее. Килүчеләр, кызыксынучылар бик күп. Тик музейның статусы һаман да билгеләнмәгән, Татарстан дәүләт музееның бер бүлеге итеп расланмаган, штатлар да бирелмәгән. Димәк, киләчәге билгесез дигән сүз. Мин генә түгел, халык та борчыла. Үземә дә: «Безнең музей республикабызга кирәкми икән, аны Чуашстанга сатыйк», – дигән сүзләр җиткерделәр. Мин алар белән килешә алмыйм бит инде. Югыйсә анда бик күп тарихчылар, язучылар, журналистлар булып китте. Барысы да яхшы бәя бирделәр. Музейның статусын үзгәртүне сорап, Президентыбызга хат та юлладылар. Анда 36 шәхеснең имзасы куелган иде.

:: Ни өчен Чуашстанга сату турында сүз чыккан, дөреслеккә туры киләме ул?

– Бу безнең тарихка бәйле. Әти миңа: «Борынгы бабабыз Муса исемле булган. Аны көчләп чукындырып, Моисей дигән исем кушканнар. Дөреслекне ачыкла, улым», – дип, гел әйтә иде. Казан архивында мәгълүмат таба алмадым. Чабаксарга барырга тәкъдим иттеләр. Чөнки Гөбенә елгасының сул ягында урнашкан керәшен авыллары кайчандыр Чуел (Цивильск) өязенә кергән булган. Баксаң, Чабаксардагы архивларда безне бөтен җирдә чуаш дип язганнар икән. Югыйсә без чуашча сөйләшә дә белмибез бит. Мәскәүгә Россиянең борынгы язмалар архивына киттем. Шунда Алиш бабамны, уллары Тутай белән Әсәнне, аның балаларын, Муса, Сәет бабайларны таптым. 1710 елгы җанисәп вакытында ирләр генә язылган. Эзләнә торгач, 1717–1722 еллардагы ревизияләрне таптым. Авыл халкының бер өлешен – татар, икенче өлешен чуаш дип теркәгәннәр. Шуны ачыкладым: рус исеме кушылганнары – чуашлар, татар исемлеләре татарлар булып язылган. Бер миссионер үзенең хезмәтендә: «Чукындырылган татарларның милләтен ни өчен чуаш дип куюлары аңлашылмый», – дип тә язган. Безнең авылда мәчет тә булган. Аны Яшел Үзән районындагы Айдар авылына илтеп салганнар. Чукындыру чорында безгә мөселман ягыннан килеп булышучы аз булган. Хәзерге Яшел Үзән районының Айдар, Ислам, Күгәй, Күгеш авылларыннан гына килгәннәр.

:: Ни өчен нәкъ менә шушы авыллар?

– Риваятьләрдә Күгәйнең Хуҗа Хәсән улы булуы әйтелә. Күгеш, Айдар, Ислам исә – оныклары. Алар безгә ярдәм кулы сузганнар, акчалата да ярдәм иткәннәр. Ләкин Чуел өязеннән килеп, аларны туктатканнар. Бу хакта шактый документларга тап булдым.

:: Ярдәмгә мохтаҗ булгач, димәк, чукындыру процессы халык җилкәсенә авыр таш булып төшкән, дип фаразларга кала?

– Документлардан күренгәнчә, бу чорда халык саны бик кимегән. Бала тапмаска тырышканнар, күрәсең. Гомер буена яшәгән җирләрен дә калдырып китеп барганнар. Әмма икенче ягы да бар: чукынган халыкка акча түләгәннәр, армиядән азат иткәннәр, өстәмә җир биргәннәр.

:: Чукындыру өчен авылларны ничек сайлап алганнар?

– Петр I властька килгәч, рус дәүләтен ныгыта башлый. Дөньяда зур православие дәүләте төзергә тели. Башта ул татар милләтенә бик кагылмый әле. 1710 елда безнең авылда 2–3 гаилә генә чукындырылган була. Ә менә күрше чуаш авылларының якынча 70 проценты бу бәлагә тарый. Шул ук вакытта мәҗүсилекне өстенрәк күргән чуашлар өчен дә православие ят дин булып санала. Алар, төркем-төркем булып, исламга күчә башлый. Бу хәл миссионерларны уйга калдыра: татарларның үзләрен дә чукындырырга кирәк, дигән фикергә киләләр. Шул рәвешле чуашка якын татар авыллары бу хәлгә беренче чиратта дучар була. Безнең авылны өч яктан – чуаш, бер яктан урыс авылы әйләндереп алган. Димәк, буйсындырырга бик җиңел булган дип фаразларга мөмкин. 1741 елның сентябрендә патшабикә Анна Иоанновна Түбән Новгород, Казан губерналарына махсус руханилар җибәрә. 1752 елгы язмаларда безнең авыл кешеләре барысы да рус исемнәре белән теркәлгән. Тирә-яктагы халыкны чукындыру өчен, Свияжскидагы Богородицкий монастыренда «Яңа чукындырылганнар комиссиясе» төзелә.

:: Шулай булуга карамастан, соңрак авыллар яңадан ислам диненә кайта. Фаҗигале чорны хәтерләтеп, керәшен зиратлары гына әлегә кадәр шом таратып утыра. Бу хәлләргә кайчан һәм кем тарафыннан чик куела?

– Татар халкын бу бәладән патшабикә Екатерина II коткара. Ул «яңа чукындырылганнар конторасы»н, канцелярияне яптыра.

:: Бу хакта сүз чыкса, күпме вакыт үткән бит инде, нигә кирәк, дип әйтүчеләр дә шактый. Казан ханлыгына кадәр керәшеннәр православие динендә булган, диючеләр дә бар...

– Болгарга 922 елны ислам керсә, Русьта православие 66 елга соңрак кабул ителә. Шулай булгач, православие динендә ничек була алган соң алар? Болгар дәүләте заманында татарлар һәм Идел-Урал төбәгендә яшәүчеләрнең бер өлеше – мәҗүсиләр, калганнары ислам динендә булган. Ә нигә кирәк инде бу, дип йөрүчеләр, чыннан да, бар. Аларга тыныч яшәргә кирәк, әби-бабаларының нинди хәсрәт чигүләрен онытканнар. Шулай сөйләп йөрүчеләр арасында Мамадыш, Питрәч, Минзәлә, Тукай, Балык Бистәсе, Алабуга керәшеннәре күп. Әйе, алар бездән элегрәк, Иван Грозный чорында чукындырылганнар. Ул яклардан Казанны алырга 1552 елны, Пермь татарларын һәм русларны җыйнап, Бәхтияр Дизюлин килә. Кем Казанны яуларга бармаган, шуларны чиркәүгә кerткәннәр. Бу чорныкылар «старокрещенный» дип атала, без – «новокрещенныйлар».

:: Шулай да керәшеннәргә хас үзенчәлекләрне, мәсәлән, җырларны, киемнәрне сез ничек аңлатасыз? Хәтта аерым теле бар диючеләр дә юк түгел бит...

– Чукындырылганнан соң, исламда булган халыкны массадан аерып алып, рус дәүләтенә хезмәт итү өчен тәрбияләргә теләгәннәр. «Хәзер инде сез татар түгел, чуаш булдыгыз», – дигәннәр. Ә татарлар исә: «Милләтегезне саттыгыз», – дип битәрләгәннәр. Ике якка да юл ябылып, әби-бабайлар бик авыр хәлдә калган, дип уйлыйм. Түбәтәйне салырга туры килгән. Чуаш дип язылгач, киемнәрне дә аларныкына охшатып кияргә мәҗбүр иткәннәрдер инде. Төп милләттән аерып, читләргә көчләп кушу әби-бабайлар өчен бер дә җиңел булмагандыр. «Керәшеннең акылы керәле дә чыгалы» дигән әйтем дә шуннан калгандыр. Бернинди гаепләре булмаса да, аларга кимсетеп караганнар. Югыйсә безнең бабаларыбыз чукынмаганнар, ә көчләп чукындырылганнар. Боларның икесе – ике нәрсә. Ә телгә килгәндә исә, аерым тел, әлбәттә, юк инде. Кайбер сүзләрне башкача әйтү ул – диалект кына. Башка милләтләрдә, мәсәлән, русларда да андый аерымлыклар бар. Тел турында сүз чыккач, шунысын да әйтеп китим. «Керәшен татары» дип атау, минемчә, дөрес түгел. «Татар керәшене» кирәк. Керәшеннең татары юк, ә татарның керәшене бар чөнки. Минемчә, «чукындырылган татарлар» дип атау тагын да дөресрәк булыр иде.

:: Хуҗа Хәсән авылын мин үзем дә бик якын күрәм, чөнки аның оныгы Айдар нигез салган авылда туып-үстем. Элек, хәтерлим әле, әби-бабайлар, әти-әниләр, җигелгән атка төялеп: «Бабай каберен зиярәт кылып кайтабыз», – дип чыгып китәләр иде. Редакция биреме белән Кайбыч районына килеп чыкканда, гел кагылып китәргә тырышам. Ул вакытта анда, гәрчә бабалары Хуҗа Хәсәннең авыл кырыендагы каберен карап торсалар да, татар булуларын инкарь итеп, «без керәшеннәр бит» дип горурланып сөйләшәләр иде. Хәзер инде тикшеренүләр үткәрдегез, татар булуыгызны исбатладыгыз. Авыл халкының мөнәсәбәте ничек?

– Әйткәнемчә, каршы чыгучылар булгалады. Әмма архив документларына нигезләнгән тарихка каршы килеп булмый. Музейда бу хакта теләсә нинди белешмә алырга була. Ата-бабалар үткән юлны барлап, тарихи дөреслекне кайтару юлыннан тайпылырга исәбем юк.

:: Әңгәмә башында әйтелгән проблемаларны ничек хәл итәргә җыенасыз?

– Бәлки, ишетерләр, дигән теләктә калам.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Йокымы, укумы?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Әти-әниләргә дә, балаларга да уңайлы. Программаны үтәп өлгерәбез, әти-әниләрнең берсе дә зарланмый. Бернинди кыен якларын да күрмибез. Дөрес, кайбер көнне балаларга 7–8 дәрес тә укырга туры килә. Әмма балалар ял итеп укый, озын тәнәфесләр дә бар. Дәрестә укытучылар күнегүләр дә ясатып ала. Укучылар көнгә өч тапкыр ашый. Балалар мәктәптән арып кайта дип әйтеп булмый, – диде мәктәп директоры Розалия Козловская.

Биш көн укытканда, туган тел сәгатьләре кыскара, дип борчылучылар да бар. Шуңа күрә директордан бу сорауга да ачыклык керттек.

– Укучылар арасында татар, рус, башка милләт балалары да бар. Алар барысы да иврит телен өйрәнә. Бездә татар теле сәгатьләре укытылмый. Әти-әниләргә, балагызны татарча укытасыгыз килсә, татар мәктәбенә барыгыз, дип тәкъдим итәбез. Казанда андый мәктәпләр бар, – диде ул.

Районнарда биш көнлек уку әти-әниләрне ни дәрәҗәдә кызыксындыра икән? Сарман районы мәгариф идарәсе башлыгы Гөлшат Идрисовадан шул хакта сораштык. Аның әйтүенчә, районда әлегә андый бер генә мәктәп тә юк.

– Бу тема минем өчен дә актуаль. Соңгы атналарда башлангычта биш көнлек укулар турында уйлап йөрим. Шәһәрдән аермалы буларак, без – авыл районы. Җәлил бистәсе шәһәр тибында булса да, күпчелек халык авылга кайтып-китеп йөри. Әти-әниләр каядыр чыгып киткән очракта, ун яшьлек баласын үзен генә калдыра алмый. Шуңа күрә үзләре белән алырга тиеш. Алып китә алмыйлар, чөнки балаларының укыйсы бар. Әти-әниләр ял иткәндә, баланы шимбә укуга озату – алар өчен мәшәкать. Менә шул ике сәбәп өчен биш көнлек укытуга күчү турында сүз кузгаталар, – ди Гөлшат Идрисова. – Минем уйлавымча, башлангыч сыйныф укучысына көнгә җидешәр сәгать уку шимбә мәктәпкә барып кайтуга караганда авыррак. Бер яктан, балаларның ял итүе дә кирәк. Көнлек нагрузканы киметү өчен кайбер дәресләр төшеп калырга мөмкин. Без әле биш көнлек укытуга күчәргә җыенмыйбыз, ләкин андый уйлар бар. Әгәр әти-әниләр теләк белдерә икән, без каршы түгел.

Марат ЛОТФУЛЛИН, Мәгарифне үстерү институты доценты, физика-математика фәннәре кандидаты:

– Биш көнлек укытуның бары бер генә тискәре ягы бар – болай укыганда туган телне укытып булмый, аңа вакыт каралмаган. Беренчедән, СанПиНны кыскарттылар, сәгатьләр саны азайды. Икенче яктан, Россия Мәгариф министрлыгы үрнәк уку планнарына туган тел укытылмый торган укыту планнары кертте. Бу инде биш көнлеккә күчәргә мөмкинлек бирә. Туган телне укыту һәм укытмауны мәктәп директорлары хәл итә. Әгәр әти-әниләр һәм мәктәп биш көнлек укытуны сайласа, ул вакытта туган телләр укыта торган уку планын сайлап булмый, сәгатьләр саны җитми. Әгәр туган телне укыйсыгыз килә икән – алты көн укыйсыз, укыйсы килмәсә, биш көнгә күчәсез инде.

tatarstan.ru

КУНАК АШЫ

ТУРИСТЛАР САНЫ 50 ПРОЦЕНТКА АРТКАН

Көтеп алган кунак кадерле, ди халык. Кунаклар яраткан Татарстан өчен бигрәк тә. Бу елның 8 аенда республикага килгән туристлар саны да, узган елгы күрсәткечләр белән чагыштырганда, 50 процентка диярлек үскән ди әнә. Моңа инде эчке туризмның популярлашуы да, Татарстан һәм аның башкаласының кунаклар өчен кызыклы булуы да тәэсир иткәндер.

Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Айгөл Балахонцева хәбәр иткәнчә, 2021 елда туристлар саны 3,3 млн кеше булган. 2020 елгы күрсәткечтән 74 процентка зуррак бу. Бу елның 8 аенда Татарстан һәм башкалага килгән туристлар саны 48 процентка арткан.

– Туристлар өчен аеруча кызыклы булган урыннарда, әйтик, Болгарда, кунаклар саны 154 процентка үсте. Җәй айларында туристлар агымы 30 процентка артты, – дип саннар белән куандырды Айгөл Балахонцева.

Моннан тыш Казан Кремленә – 2,6 млн, Зөя утрау-шәһәрчегенә – 1 млн, Болгарга – 855 мең, Алабугага – 375 мең, Чистайга 134 мең турист килгән.

Кешеләре күп булгач, баш өстенә түбә тәкъдим иткән урыннарга да ихтыяҗ зурдан булган дигән сүз инде. Айгөл Балахонцева сүзләренчә, кунакханәләргә эш 8 процентка арткан.

Ә Казаннан кайсы тарафларга күбрәк очканнар соң? «Казан» аэропортының стратегик үсеш буенча директоры Андрей Лопатин әйтүенчә, бу елның 8 аенда Мәскәү һәм Анталиягә очучылар аеруча күп булган.

– Ил эчендәге очышлар буенча Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи, Новосибирск, Кавказ Минераль суларына рейслар популярлар рәтендә булды. Халыкара очышларга килгәндә, башкала аэропортыннан Анталия, Истанбул, Дубай, Дүшәнбе, Худжанд шәһәрләренә очучылар күп булды, – дип аңлатты ул.

Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Айрат Садыйков сүзләренә караганда, һава юлларын сайлаучылар санын арттыруга ирешкәннәр. Дөрес, бу БДБ илләренә очу хисабына. Чит илләргә рейслар арту түгел, кимүгә таба юнәлгән, билгеле.

– Татарстанның өч аэропорты аша бу елның 8 аенда 3 млн пассажир узды. Бу былтыргы күрсәткечтән 1 процентка күбрәк. 70 төрле юнәлеш буенча очыш ясарга мөмкин. Шуларның 12се – БДБ илләрен, 6сы – халыкара маршрутлар, 60 юнәлеш – ил эчендә, – дип аңлатты министр урынбасары.

Сәяхәт итәргә яратучылар өчен яңалык та бар. Шушы арада Казаннан чит илләргә яңа авиарейслар оештырыла башлар дип көтелә.

– 2022–2023 елның кышкы сезонында яңа рейслар барлыкка килә. Аерым алганда, атнага ике тапкыр Белградка, шулай ук Тель-Авив, Тегеран, Иркутск, Новокузнецк шәһәрләренә рейслар оештырылачак, – дип сөйләде Габдулла Тукай исемендәге «Казан» аэропорты генераль директоры Сергей Романцов. Әлегә бу рейсларның төгәл көннәре билгеле түгел.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Спорт

Бер утырып сөйләшкәч

«Ак барс» яңа сезонда беренче җиңүен яулады. Казан командасы Мәскәүдә Гагарин Кубогының хәзерге иясе ЦСКАдан өстен чыкты. Олег Знарок уенчылары көндәш капкасына 5 алка кертте, тик иң көчле саналган уенчылар әлегә эшкә керешә алмый интегә.

Яңа сезон башланыр алдыннан спорт сайтларының берсе КХЛдагы иң яхшы уенчылар исемлеген игълан итте. 25 хоккейчы арасына «Ак барс»тан 4 уенчы эләккән: һөҗүмчеләр Александр Радулов, Вадим Шипачев, Станислав Галиев һәм сакчы Вячеслав Войнов. Болар барысы да – Казан командасына әле быел гына килеп кушылган егетләр. Радулов – соңгы елларда НХЛда уйнап кайтты, хәзер исә КХЛда төп «йолдыз» санала. Шуңа күрә аның рейтингның беренче баскычында урнашуы гаҗәп тә түгел. Белгечләр һөҗүмче, уртача алганда, һәр матч саен бер очко җыяр дип фаразлый. Шипачев исемлектә икенче урында урнашкан. «Динамо»да уйнаганда ул өч ел рәттән лиганың иң нәтиҗәле уенчысы саналды. Дүрт тапкыр 60тан күбрәк очко җыйды. Ул да үз урынында, кыскасы. НХЛдан кайткач, СКА, «Авангард» һәм «Динамо»да чыгыш ясаган Вячеслав Войнов КХЛда иң шәп сакчылардан санала. Ул – Олимпия чемпионы, ике мәртәбә – Стэнли, бер тапкыр Гагарин Кубогы иясе булып танылган кеше. Рейтингта унынчы урында урнашкан. «Ак барс» белән 2018 елда Гагарин Кубогын яулаган Станислав Галиев ул елны плэй-оффта иң күп алка керткән хоккейчы да булып танылган иде. Узган сезонны һөҗүмче «Динамо»да уздырды һәм янә иң нәтиҗәле уенчыларның берсе булды. Җәй көне Мәскәүне Казанга алмаштырган хоккейчы рейтингта унбишенче урында урнашкан.

Тик «Ак барс»ның яңа сезондагы тәүге матчында бу егетләр берни майтара алмады. Казан командасы Мәскәүдә «Динамо»га 0:2 исәбе белән оттырды. Әлеге җиңелү хоккей дөньясында бу көннәрдә иң еш телгә алынган вакыйгаларның берсе булды. Аңлашылганча, тәнкыйть сүзләре күп әйтелде. Имеш, «йолдыз»лардан команда килеп чыкмаган, алар бары үзләре турында гына уйлый. Хәтта 2004 елда НХЛ хоккейчыларыннан тупланган уңышсыз составны да искә алучылар булды. Кызып китеп, былтыргы тренер Дмитрий Квартальновны сагынучылар да табылды. Шуңа күрә «Ак барс» белән ЦСКА арасындагы уенда Мәскәү ягының өстен чыгасын фаразлаучылар да күбрәк булды. Җитмәсә, алдагы ике уенда бу команда көндәшләре капкасына 11 алка кертергә өлгерде.

«Ак барс»та исә җыелыш уздырганнар. Ни хакында сөйләшкәннәрен әйтмәсәләр дә, чамаларга була инде. «Шуңа күрә бу уенга бөтенләй башка теләк белән чыктык», – диде баш тренер Олег Знарок, командасы гамәлдәге чемпион ЦСКА капкасына биш алка керткәч. Барыннан да бигрәк Александр Радуловның теләге көчле булып чыкты. КХЛның иң хисле уенчысы үзен дә, көндәшләрен дә кызганмады, иптәшләре белән дә әйткәләште. Аннары аны беренче өчлектән икенчесенә дә күчерделәр. Файдасы булды! Ахыр чиктә Радулов барыбер үз дигәненә иреште һәм матчның өченче периодында командасының өченче алкасын кертте. Белгечләр исәпләп чыгарган: КХЛда ул соңгы мәртәбә 2342 көн элек алка керткән икән! Ул вакытта һөҗүмче ЦСКАда уйный иде. «Беренче матчта начар уйнадык. Сезонны начар башладык – үзебез гаепле. Шуңа күрә икенчесендә дә җиңеләсе килмәде», – диде ул очрашудан соң.

Беренче алканы исә Мәскәү командасы кертте. Казан хоккейчылары беренче период ахырында исәпне тигезләде, икенчесендә өстенлекне үз кулларына алып, тагын бер мәртәбә уңышка иреште. Алкалар Илья Сафонов белән Кирилл Панюков исәбендә. Алар да, очрашуда бишенче алканы керткән Никита Дыняк та бүгенге «Ак барс»та төп уенчылар өммәтендә йөрми. ЦСКАга каршы очрашуның язмышын бу егетләр һәм капкачы Тимур Билалов хәл итте. «Йолдыз»лар кайчан эшкә керешер? Бу сорау ике уенда бер очко да җыя алмаган Вадим Шипачевка кагыла. Олег Знароктан да сорадылар. Ул борчылмаска киңәш итә. «Шипачев үзенә урын таба алмый интегә дип әйтмәс идем. Ул үз эшен башкара, һөҗүмчеләргә ярдәм итә. Икешәр алка кертергә тиеш түгелдер бит инде? Әлегә безнең бер генә проблема бар: бер кешегә күбрәк булганда алка кертү. Башка проблема күрмим, – диде ул очрашудан соң. – Бу башы гына. Барысы да алда әле». Знарок үз егетләрен яклый. Сәбәбе аңлашыла. Тарткалаша башласалар, яхшы уенчылардан команда килеп чыкмаячак.

Киләсе очрашуны «Ак барс» 9 сентябрьдә үз бозында «Адмирал»га каршы уздырачак.

КӨНЧЫГЫШ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

	команда	уен	очко
1	Автомобилист	2	4
2	**Ак барс**	**2**	**2**
3	Адмирал	2	2
4	Амур	2	2
5	Сибирь	2	2
6	Металлург	2	2
7	Салават Юлаев	2	1
8	Барыс	2	1
9	Нефтехимик	2	1
10	Авангард	2	0
11	Трактор	2	0

ak-bars.ru

УНСИГЕЗЕНЧЕ СЕРИЯ

КАЗАНДА ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ БАШЛАНА

Кино гына димә. XVIII тапкыр үткәреләчәк мөселман киносы фестивале – фильмнар карау һәм бәяләү генә түгел, кино өлкәсе өчен белгечләр әзерләү, милли кино индустриясенең җитешле һәм җитешсез яклары турында фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу өчен менә дигән форсат. Быелгы фестивальнең нинди үзенчәлекләре бар? Без бу һәм башка сорауларга җавап табарга тырыштык.

«Татар-информ»

Кемнәр килә? Бу сорауга Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова җавап бирде. Кунаклар арасында соңгы вакытта Россия белән мөнәсәбәтләр катлауланган илләр дә бар.

– Катнашучыларга килгәндә, бераз шикләребез булса да, дөньяның 44 иленнән барлыгы 625 гариза кабул иттек. Фестивальгә исә Үзбәкстан, Казахстан, Таҗикстан, Иран, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, шулай ук Австралия, Алмания һәм Франциядән 130лап кунак көтәбез, – диде ул Хөкүмәт йортында узган брифингта.

Мәдәният министры быелгы фестивальнең Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысасында узуын, шуңа бәйле рәвештә тагын да дәрәҗәлерәк булуын искәртте.

Кемнәр бәяли? Быел да фестивальдә тәкъдим ителәчәк фильмнарны төрле илләрдән танылган кино тәнкыйтьчеләре, режиссерлар бәяләячәк. Алар – Хәмид Бенамра (Алжир, Франция), Анара Кашаганова (Казахстан), Әмир Салмин Әл Мурри (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), Нәркис Абьяр (Иран), Хаобам Пабан Кумар (Һиндстан), Ихсан Кабил (Төркия), Илһам Шаһин (Мисыр), Валерий Фомин (Россия), шулай ук Россия Ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин. Жюри комиссиясе рәисе – Россиянең халык артисты Владимир Хотиненко.

Татарстан нәрсә күрсәтә? Үзебезнең режиссерларга килгәндә, быел алар фестивальгә 40лап кинокартина тәкъдим иткән, 14 фильм программага кертелгән. Халыкара конкурста Казахстан белән берлектә төшерелгән «Тарлан» (реж. – Юлия Захарова), «Галиябану» (реж. – Рифат Миндубаев), «Габдрахман» (реж. – Марсель Мәхмүтов), «Сосновый ключ» (реж. – Булат Минкин) фильмнары, ә милли конкурста «Без – 41 нче ел балалары» (реж. – Әмир Галиәскәров), «Республика 99» (реж. – Адель Таккезе, Юлия Захарова, Софья Силкина), «Параллели» (реж. – Сергей Батаев), «Посланник» (реж. – Зөфәр Хәйруллин), «Одна в горах» (реж. – Азат Дәүләтшин), «Настала ночь» (реж. – Әмир Сальянов), «Дядя Миша» (реж. – Ахмаджон Оев), «Татарский край. Троицк» (реж. – Александр Далматов), «Коридор воспоминаний» (реж. – Чыонга Тхе Тхиен), «Таш» (реж. – Елизавета Елисеева) кинокартиналары катнашачак.

Кайда һәм кайчан? Быел фестиваль кысасындагы чаралар барлыгы тугыз мәйданчыкта уздырылачак. Фильмнарны (ә аларны теләгән һәркем карый алачак) «Республика» сәүдә үзәгендә урнашкан «Синема 5» кинотеатрында күрсәтәбез, диделәр. Тантаналы чаралар исә Казан Ратушасында һәм «Пирамида»да узачак. Шулай ук кайбер чаралар Милли китапханә, Заманча сәнгать галереясы, Милли музей, «Әкият» балалар үзәге, Казан мәдәният институтында да булыр дип көтелә.

Тагын ниләр көтелә? Мөселман киносы фестивалендә фильмнар гына күрсәтеп калмаячаклар, билгеле. Фестивальнең башкаручы директоры Миләүшә Айтуганова сүзләренә караганда, соңгы биш елда фестивальнең эшлекле программасына да игътибар зурдан күрсәтелә.

– Быел питчингка (билгеле бер кинопроектны финансларга әзер инвесторлар табу максатыннан тәкъдим итү. – **Ред.**) 12 илдән 56 гариза килде. Алар барысы да Татарстан белән хезмәттәшлек итәргә әзер булган продюсерлар, кинокомпанияләр һәм башкалар. Игътибар елдан-ел арта. Ә мондый чара Татарстан кинематографиясенә яңа мөмкинлекләр ача, халыкара кино базарында үзен күрсәтергә ярдәм итә, – диде ул.

Халыкара питчинг Татарстан катнашында төшерелгән фильмнарны башка илләрдәге прокатка чыгарырга да ярдәм итәчәк, дип өметләнәләр. Насыйп булса, бәлки үзебезнең фильмнарны үзебез дә карарбыз.

Фестивальнең тагын бер миссиясе – кадрлар мәсьәләсен хәл итү, ди Ирада Әюпова. Шуңа күрә быел Казан мәдәният институтында кино мәктәпләре форумы эшләячәк. Кино өлкәсе өчен белгечләр әзерли торган 14 уку йорты катнашыр дип көтелә.

Шулай ук 8 сентябрьдә Татарстанның Милли китапханәсендә Россиянең халык артисты Ренат Ибраһимовны искә алачаклар һәм ул катнашкан фильмнарны күрсәтәчәкләр. Моннан тыш, фестиваль кысасында Россиядәге джаз сәнгатенең 100 еллыгына багышланган чара уздырырга ниятлиләр. Анысы 9 сентябрьдә Милли музейның ишегалдында булачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Үрнәк

ӨЕНДӘ МУЗЕЙ ЯСАГАН РУШАНИЯ НИЗАМОВА:

«ЯРАТКАН КЕШЕ ГЕНӘ ЭШЛИ АЛА МОНЫ»

Аксубай, Яңа Дума

Нәрсә белән генә шөгыльләнсә дә, хезмәтеннән тәм табып, илһамланып яши Рушания Низамова. Аксубай районының Яңа Дума авылында яшәп иҗат итүче балалар язучысы – бар яктан килгән шәхес: язу-сызу эше дисеңме, җырлау-биюме, гармун тартып җибәрүме – барысын да булдыра. Өендә Нәҗип Думавига багышлап, музей да ясап куйган. Үзенчәлекле музейны без дә күреп кайттык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Казанда укыганда Габдулла Тукай, Максим Горький музейларына йөрергә ярата идем. Шишкин музеен күрү өчен, Алабугага махсус бардым. Шулай бөтен музейларны карап чыккач, нишләп әле миңа да ясамаска, дигән уй килде, – дип сөйли башлады Рушания апа.

Туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлап, бер ел колхозда эшләгәч, Рушания апа Казанга киномеханиклар мәктәбенә укырга киткән. Аны тәмамлагач, бер елдан соң Аксубайның Югары Баланда авылында киномеханик булып эшли башлаган. Үз авылларында яңа ачылган кичке мәктәптә киномеханиклар түгәрәген оештырган. Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, туган авылы Яңа Думага әйләнеп кайтып, мәктәптә татар һәм гарәп телләрен укыткан. Бүген мәктәптә эшләүче музей да Рушания апаның тырышлыгы белән барлыкка килгән.

– Мәктәпнең икенче катында кечкенә генә бер бүлмәдә музей ясадым. Фанерадан мич, бишек ясадым, лампалар, самаврлар куйдым. Хәзер аякларым авырта, мәктәпкә кадәр барып җитә алмыйм. Шуңа музейны үз өемдә ачарга булдым, – ди ул.

Нәҗип Думавиның якташы буларак, музейны аңа багышлаган. Яза, сыза, буйый – барысын да үзе эшли Рушания апа.

– Бу эшне шулкадәр яратам. Яраткан кеше генә эшли ала аны, – ди ул, елмаеп. – Бөек шәхесебез Нәҗип Думави турында күп нәрсә эшләп була. Аның шәҗәрәсен төзедем, бөтен биографиясен укып, оныкларыннан, туганнарыннан сорашып, мәкаләләр яздым. Соңрак «Нәҗип – Дума егете» поэмасы барлыкка килде. Шул китапка Аксубайдан бер рәссамнан иллюстрацияләр ясаттым, – ди язучы.

Музейның берничә почмагында Дума авылының күренекле шәхесләре, тырыш хезмәтчәннәре рәсемнәре урын алган. Мәктәп директорлары, табиблар, шагыйрьләр, район башлыклары, механизаторлар – берсе дә калмаган. Мөгаллимнәр, укытучылар турында аерым бер җылылык белән сөйли Рушания апа. Чөнки үзе дә тормышының кырык елын балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган.

– Илматова Мәрьям апа – мулла кызы, кияүгә чыгып, безнең авылда калган. Бездә татар теле һәм рәсем дәресләрен укытты. Әдәбиятка юнәлешне ул бирде миңа. Миндә иҗатка мәхәббәт уяткан кеше, бик яхшы мөгаллим иде. Аның кебек зыялы, һөнәренә тугры кешеләр сирәк була, – ди Рушания апа, яраткан укытучысын искә алып.

Укытучылык, язучылык эше белән шөгыльләнеп китүе һич гаҗәп түгел. Чөнки белем алуга, китапка мәхәббәте балачактан ук килә. «Кечкенәдән китап җыйдым. Китапханәдән алган китапны укып бетергәч, кире бирергә кирәк бит. Аларны бирмәс өчен елый идем мин хәтта. Аннары шулай китаплар җыя башладым, үземнең кечкенә генә китапханәмне булдырдым», – ди.

Музейга үзенең истәлекләрен дә куярга онытмаган. Туксанга якын грамота, Россиянең атказанган укытучысы таныклыгы, хезмәт ветераны медале, Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия – Рушания апаның күп еллар буе әдәбият һәм белем бирү өлкәсендә хезмәт куюының нәтиҗәләре.

– Минем өчен иң кадерлесе – Язучылар берлеге әгъзасы таныклыгы. Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия дә бик кадерле. Һәркемгә бирмиләр бит аны, – ди язучы.

Рушания апаның тормыштагы иң зур сөенече – улы Фәнис. Ул – авыл мәчетендә мулла. Бер-берсенә терәк булып, бик матур яшиләр. Әнисенең эшен дәвам итеп, улы да укытучылык юлын сайлаган. Җырбию, гармунда уйнау, шигырь-хикәяләр язу – икесенең дә яраткан шөгыльләре.

Рушания апа бик оста итеп рәсемнәр дә ясый әле. Үз картиналарында авылын, Нәҗип Думави эшләгән мәчетне, нарат-лык, бакча, чишмә буйларын сурәтләгән.

Күркәм, матур сыйфатлары белән үзләренә тартып торучы, сокланасы, үрнәк аласы килгән кешеләр була. Рушания апа да – әнә шундый шәхесләрнең берсе. Авылдашлары аның турында горурланып сөйли. «Аның дәресләре искиткеч иде. Дәрескә рәсемнәрне үзе кичтән ясап алып килә, без шаккатып тыңлап тора идек. Рушания апа – минем укытучым да, хезмәттәшем дә. Озак еллар буе бергә дус-тату эшләдек. Мөхтәрәм һәм бик оста кеше. Кулыннан килмәгән эше юк», – ди аның турында укучысы, Яңа Дума авылы мәктәбе директоры Энҗе Хәйретдинова.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 330

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+